# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“15” ноябрь 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 15 ноябрендә “Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан,80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Төрекләр авылы территориясен яхшырту (территорияне чистарту - Төрекләр авылында үлән чабу).
- Ремонтлау, коймалар кую, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (материаллар сатып алу, Төрекләр авылындагы зират өчен койма кую (контракт буенча эш өчен түләү, смета буенча); территорияне чистарту; зират, Төрекләр авылының үләннәрен чабу).

«РИЗА» «КАРШЫ»
мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.
Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 82 (сиксән ике) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 46 (кырык алты ) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 46 (кырык алты) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан,1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз)

сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Төрекләр авылы территориясен яхшырту (территорияне чистарту - Төрекләр авылында үлән чабу).
- Ремонтлау, коймалар кую, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (материаллар сатып алу, Төрекләр авылындагы зират өчен койма кую (контракт буенча эш өчен түләү, смета буенча); территорияне чистарту; зират, Төрекләр авылының үләннәрен чабу).

2.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Т.Гатауллин